**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан»

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 27 марта 2004 года № УП-290 «О Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 16 марта 2007 года № УП-126, от 4 июня 2012 года № УП-416, от 12 декабря 2016 года № УП-1091 и от 16 апреля 2020 года № УП-231) следующие изменения:

а) в наименовании слова «при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «при Раисе Республики Татарстан»;

б) в преамбуле слова «Закона Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан» заменить словами «Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан»;

в) в пункте 1 слова «при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «при Раисе Республики Татарстан»;

г) в пункте 2 слова «при Президенте Республики Татарстан» заменить словами «при Раисе Республики Татарстан»;

д) дополнить пунктом $2^1$ следующего содержания:

«$2^1$. Утвердить состав Комиссии по государственным наградам при Раисе Республики Татарстан (приложение № 3).»;

е) приложение № 2 изложить в следующей редакции:

«Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан
от 27 марта 2004 года
№ УП-290

### Положение
### о Комиссии по государственным наградам при Раисе Республики Татарстан

## I. Общие положения

1. Комиссия по государственным наградам при Раисе Республики Татарстан (далее – Комиссия) образуется Раисом Республики Татарстан для проведения общественной оценки материалов о награждении государственными наградами Республики Татарстан и обеспечения объективного подхода к высшей форме выражения государственного и общественного признания заслуг, рассмотрения представлений о поощрении Благодарностью Раиса Республики Татарстан, а также в целях обеспечения реализации Раисом Республики Татарстан его полномочий, связанных с награждением государственными наградами Российской Федерации, поощрением Почетной грамотой Президента Российской Федерации, благодарностью Президента Российской Федерации, Почетной грамотой Правительства Российской Федерации, благодарностью Правительства Российской Федерации и награждением ведомственными знаками отличия, дающими право на присвоение звания «Ветеран труда».

Комиссия является постоянно действующим органом при Раисе Республики Татарстан и работает на общественных началах.

2. Правовую основу деятельности Комиссии составляют Конституция Российской Федерации, Конституция Республики Татарстан, федеральные конституционные законы, федеральные законы, законы Республики Татарстан, указы и распоряжения Раиса Республики Татарстан, иные нормативные правовые акты, а также настоящее Положение.

## II. Основные функции Комиссии

3. Комиссия осуществляет следующие функции:

оценивает представления к награждению государственными наградами Республики Татарстан, внесенные Раису Республики Татарстан, и вправе изменить вид награды, указанный в представлении, с учетом заслуг награждаемого или отказать в представлении к награждению с обоснованием отказа;

представляет заключения о возможном награждении, восстановлении в правах на государственные награды Республики Татарстан, лишении государственных наград Республики Татарстан, а также заключения на подготовку проектов соответствующих правовых актов о награждении, об отмене правового акта (о внесении изменения в правовой акт) о награждении государственными наградами Республики Татарстан;

создает общественные экспертные советы по направлениям своей деятельности;

выполняет поручения Раиса Республики Татарстан;

рассматривает предложения, заявления и жалобы граждан по вопросам, отнесенным к компетенции Комиссии;

предварительно рассматривает представления о поощрении Благодарностью Раиса Республики Татарстан, внесенные Раису Республики Татарстан, и по результатам рассмотрения вносит Раису Республики Татарстан предложения о поддержке представления или отклоняет его. В случае установления оснований, предусмотренных Законом Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 74-ЗРТ «О государственных наградах Республики Татарстан» (далее – Закон Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан»), для награждения государственной наградой Республики Татарстан лица, представленного к поощрению Благодарностью Раиса Республики Татарстан, Комиссия вносит Раису Республики Татарстан соответствующее предложение;

принимает решения о выдаче дубликатов орденов, медали ордена, медалей и нагрудных знаков к почетным званиям в случаях, предусмотренных Законом Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан»;

принимает в случаях, предусмотренных Законом Республики Татарстан «О государственных наградах Республики Татарстан», решения о сохранении государственной награды за преобразованным (вновь образованным) муниципальным образованием Республики Татарстан, о сохранении государственной награды за правопреемником награжденной организации, а также о передаче государственной награды в государственный или муниципальный музей для хранения и экспонирования;

рассматривает вопросы совершенствования государственной наградной системы Республики Татарстан;

оценивает внесенные Раису Республики Татарстан документы о награждении государственными наградами Российской Федерации, поощрении Почетной грамотой Президента Российской Федерации, благодарностью Президента Российской Федерации, Почетной грамотой Правительства Российской Федерации, благодарностью Правительства Российской Федерации и награждении ведомственными знаками отличия, дающими право на присвоение звания «Ветеран труда», и представляет Раису Республики Татарстан предложения о поддержке или отклонении документов о награждении (поощрении) с обоснованием таких предложений.

## III. Обеспечение деятельности Комиссии

4. Комиссия для осуществления возложенных на нее функций имеет право:

запрашивать и получать от государственных органов и органов местного самоуправления, а также организаций и должностных лиц необходимые для своей деятельности материалы и документы по вопросам, отнесенным к ее компетенции;

заслушивать представителей государственных органов Республики Татарстан, органов местного самоуправления по вопросам применения наградного законодательства Республики Татарстан.

5. Материально-техническое, документационное, правовое и информационное обеспечение деятельности Комиссии осуществляют Управление делами Раиса Республики Татарстан и соответствующие подразделения Администрации Раиса Республики Татарстан.

**IV. Руководство и организация работы Комиссии**

6. Состав Комиссии утверждается Раисом Республики Татарстан.

7. Заседания Комиссии проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в два месяца. Заседаниями Комиссии руководит председатель Комиссии, а в его отсутствие – заместитель председателя Комиссии.

Заседания Комиссии считаются правомочными, если на них присутствует более половины ее членов.

В заседаниях Комиссии могут принимать участие представители государственных органов, органов местного самоуправления, общественных объединений, трудовых коллективов, ученые и специалисты, представители средств массовой информации.

8. Решение Комиссии принимается простым большинством голосов присутствующих на заседании членов Комиссии путем открытого голосования.

Решение Комиссии оформляется протоколом, который подписывается всеми членами Комиссии, присутствовавшими на заседании.

По решению председателя Комиссии голосование может также производиться в заочной форме путем проведения опроса членов Комиссии с занесением результатов опроса в протокол, который подписывается председателем Комиссии, а в его отсутствие – заместителем председателя Комиссии.

9. Подготовку материалов для заседаний Комиссии, проектов указов и распоряжений Раиса Республики Татарстан, контроль за своевременным исполнением принятых решений осуществляет отдел государственных наград Администрации Раиса Республики Татарстан.

_____________»;

ж) дополнить приложением № 3 следующего содержания:

«Приложение № 3
к Указу Президента
Республики Татарстан
от 27 марта 2004 года
№ УП-290

**Состав**
**Комиссии по государственным наградам при Раисе Республики Татарстан**

| | |
|---|---|
| Гарипов Ильнур Махмутович | первый заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – начальник Управления Раиса Республики Татарстан по работе с территориями, председатель Комиссии |
| Тимиргалеева Ильсия Набиулловна | заведующий отделом государственных наград Администрации Раиса Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Алеев Булат Рафаилович | руководитель Аппарата Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Валиуллова Рашида Рафиковна | заместитель директора по управлению персоналом акционерного общества «Татэнергосбыт» (по согласованию) |
| Виниченко Владислав Валентинович | заместитель министра здравоохранения Республики Татарстан |
| Гараев Раиль Рузалевич | заместитель Руководителя Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан – начальник Управления по координации взаимодействия органов исполнительной власти Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Глухова Лариса Юрьевна | начальник Государственно-правового управления Раиса Республики Татарстан |
| Губайдуллин Экзам Саматович | председатель Ассоциации «Совет муниципальных образований Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Долотказина Эльвира Рафгатовна | помощник генерального директора по работе с муниципальными органами публичного акционерного общества «Нижнекамскнефтехим» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Захарова Светлана Михайловна | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по социальной политике (по согласованию) |
| Карпов Родион Михайлович | заместитель министра промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Лаврентьев Александр Петрович | президент Ассоциации предприятий и промышленников Республики Татарстан (регионального объединения работодателей) (по согласованию) |
| Маврина Лилия Николаевна | Секретарь Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Махмутов Марсель Азатович | заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Мухамадеев Рустам Набиуллович | заместитель генерального директора по социальному развитию публичного акционерного общества «Татнефть» имени В.Д. Шашина (по согласованию) |
| Мухарлямов Руслан Робертович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Департамента Раиса Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Поминов Андрей Иванович | первый заместитель министра образования и науки Республики Татарстан |
| Салихов Кев Минуллинович | научный руководитель Казанского физико-технического института им. Е.К. Завойского – обособленного структурного подразделения федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук», академик Российской академии наук, академик Академии наук Республики Татарстан (по согласованию) |
| Фролов Алексей Михайлович | первый заместитель министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Хакимзянов Ленар Саетзянович | заместитель министра культуры Республики Татарстан |

______________».

2. Признать утратившими силу указы Президента Республики Татарстан по перечню согласно приложению.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания и распространяется на правоотношения, возникшие с 6 февраля 2023 года.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
03 июля 2023 года
№ 461

Приложение
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «03» июля 2023 года
№ 461

**Перечень**
**указов Президента Республики Татарстан, утративших силу**

1. Пункт 3 Указа Президента Республики Татарстан от 16 марта 2007 года № УП-126 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».
2. Указ Президента Республики Татарстан от 26 марта 2009 года № УП-175 «Об изменении состава Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
3. Указ Президента Республики Татарстан от 14 мая 2010 года № УП-314 «Об изменении состава Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
4. Указ Президента Республики Татарстан от 31 января 2011 года № УП-36 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
5. Указ Президента Республики Татарстан от 14 марта 2012 года № УП-202 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
6. Указ Президента Республики Татарстан от 17 апреля 2012 года № УП-258 «О внесении изменения в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
7. Указ Президента Республики Татарстан от 27 июля 2012 года № УП-621 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
8. Указ Президента Республики Татарстан от 8 февраля 2013 года № УП-89 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
9. Указ Президента Республики Татарстан от 28 июня 2013 года № УП-580 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».
10. Пункт 3 Указа Президента Республики Татарстан от 9 октября 2013 года № УП-1007 «О внесении изменений в отдельные акты Президента Республики Татарстан».

11. Указ Президента Республики Татарстан от 29 апреля 2014 года № УП-441 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

12. Указ Президента Республики Татарстан от 2 июля 2014 года № УП-629 «О внесении изменения в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

13. Указ Президента Республики Татарстан от 19 сентября 2014 года № УП-897 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

14. Указ Президента Республики Татарстан от 28 мая 2015 года № УП-498 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

15. Указ Президента Республики Татарстан от 19 января 2016 года № УП-17 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

16. Указ Президента Республики Татарстан от 18 мая 2016 года № УП-422 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

17. Абзац четвертый пункта 2 Указа Президента Республики Татарстан от 12 августа 2016 года № УП-684 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан по вопросам награждения государственными наградами Республики Татарстан и поощрения Благодарностью Президента Республики Татарстан».

18. Указ Президента Республики Татарстан от 9 ноября 2016 года № УП-987 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

19. Указ Президента Республики Татарстан от 3 февраля 2017 года № УП-96 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

20. Указ Президента Республики Татарстан от 18 июля 2017 года № УП-627 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

21. Указ Президента Республики Татарстан от 18 января 2018 года № УП-69 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

22. Указ Президента Республики Татарстан от 3 мая 2018 года № УП-351 «О внесении изменения в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

23. Указ Президента Республики Татарстан от 31 января 2019 года № УП-44 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

24. Указ Президента Республики Татарстан от 11 апреля 2019 года № УП-217 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

25. Указ Президента Республики Татарстан от 24 июня 2019 года № УП-359 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

26. Указ Президента Республики Татарстан от 20 сентября 2019 года № УП-556 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

27. Указ Президента Республики Татарстан от 24 сентября 2020 года № УП-612 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

28. Указ Президента Республики Татарстан от 4 декабря 2020 года № УП-816 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

29. Указ Президента Республики Татарстан от 15 апреля 2021 года № УП-288 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

30. Указ Президента Республики Татарстан от 29 июля 2021 года № УП-607 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

31. Указ Президента Республики Татарстан от 22 марта 2022 года № УП-216 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

32. Указ Президента Республики Татарстан от 2 ноября 2022 года № УП-780 «О внесении изменений в состав Комиссии по государственным наградам при Президенте Республики Татарстан».

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы, 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы һәм 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

б) преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

г) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пунктны өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составын расларга (3 нче кушымта).»;

е) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Президентының
2004 елның 27 мартындагы
ПУ-290 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында**
**нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында материалларга җәмәгать бәяләмәсе уздыру һәм казанышларның дәүләт һәм җәмәгать тарафыннан танылуын белдерүнең иң югары формасына объектив карашны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте белән бүләкләүгә үтенечнамәләрне карап тикшерү, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәте, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәте һәм «Хезмәт ветераны» исеме алу хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләү белән бәйле вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында оештырылды.

Комиссия Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы даими эшләүче орган булып тора һәм аның эшчәнлеге җәмәгать башлангычларында алып барыла.

2. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары, башка норматив хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә тәшкил итә.

## II. Комиссиянең төп функцияләре

3. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

Татарстан Республикасы Рәисенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләрне бәяли һәм, бүләкләнүченең казанышларын исәпкә алып, үтенечнамәдә күрсәтелгән бүләкләүнең төрен үзгәртергә яисә, кире кагуның сәбәбен нигезләп, бүләкләүгә тәкъдим итүне кире кагарга хокуклы;

бүләкләү мөмкинлеге, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге алуга хокукны торгызу, Татарстан Республикасы дәүләт бүләгеннән мәхрүм итү турында бәяләмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында, Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында указы үз көчен югалткан дип тану турында (указга үзгәреш кертү турында) тиешле дәүләт актлары проектларын әзерләүгә бәяләмәләр бирә;

үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча иҗтимагый эксперт советлары төзи;

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләрен үти;

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча гражданнар тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карап тикшерә;

Татарстан Республикасы Рәисенә бирелгән Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте белән бүләкләү турындагы тәкъдимнәрне алдан карый һәм карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Рәисенә бүләкләүне хуплау турында тәкъдимнәр бирә яисә аларны кире кага. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге Татарстан Республикасы Законында (алга таба – «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы) каралган җитәрлек нигезләр булган очракта, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән затны Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү өчен тиешле тәкъдимне Комиссия Татарстан Республикасы Рәисенә бирә;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда орденнар, орден медале, медальләр һәм мактаулы исемнәргә күкрәк билгеләре дубликатларын бирү турында карар кабул итә;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда Татарстан Республикасының үзгәртеп корылган ( яңа төзелгән) муниципаль берәмлегенең дәүләт бүләген үзендә калдыру, бүләкне бүләкләнгән оешманың хокукый варисында калдыру, шулай ук дәүләт бүләген саклау һәм экспозициягә кую өчен дәүләт яисә муниципаль музейга тапшыру турында карарлар кабул итә;

Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләү системасын камилләштерү мәсьәләләрен карап тикшерә;

Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Президентының рәхмәте, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Мактау грамотасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең рәхмәте һәм «Хезмәт ветераны» исеме алу хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләү турындагы Татарстан Республикасы Рәисенә бирелгән документларны бәяли һәм бүләкләү турындагы документларны хуплау яисә кире кагу турында тәкъдимнәрне, мондый тәкъдимнәрне нигезләп, Татарстан Республикасы Рәисенә бирә.

## III. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү

4. Комиссия үзенә йөкләнгән функцияләрне башкарганда түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча үзенең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле материалларны һәм документларны соратып алырга;

Татарстан Республикасының бүләкләүләр турындагы законнарын куллану мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре фикерләрен тыңларга.

5. Комиссия эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар белән, хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең тиешле структур бүлекчәләре башкара.

**IV. Комиссия эшенә җитәкчелек итү һәм аның эшен оештыру**

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан расланa.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә ике айга бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышларына Комиссия рәисе, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

Анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, Комиссия утырышлары гамәлгә хокуклы санала.

Комиссия утырышларында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар, хезмәт коллективлары вәкилләре, галимнәр һәм белгечләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

8. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә.

Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары кул куя.

Комиссия рәисе карары буенча тавыш бирү шулай ук Комиссия әгъзаларыннан сораштыру рәвешендә читтән торып та уздырылырга мөмкин, сораштыру нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, аңа Комиссия рәисе, ә ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары кул куя.

9. Комиссия утырышлары өчен материалларны, Татарстан Республикасы Рәисе указлары һәм боерыклары проектларын әзерләүне, кабул ителгән карарларның үз вакытында үтәлүенә контрольне Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге башкара.

___________»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Президентының
2004 елның 27 мартындагы
ПУ-290 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы**
**Дәүләт бүләкләре комиссиясе**
**составы**

| | |
|---|---|
| Гарипов<br>Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы, Комиссия рәисе |
| Тимергалиева<br>Илсөя Нәбиулла кызы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт бүләкләре бүлеге мөдире, Комиссия рәисе урынбасары |
| Алиев<br>Булат Рафаил улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Вәлиуллова<br>Рәшидә Рафикъ кызы | «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте директорының персоналга идарә буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Виниченко<br>Владислав Валентинович | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Гәрәев<br>Раил Рузәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы |
| Глухова<br>Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы |
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Долотказина<br>Эльвира Рәфгать кызы | «Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының муниципаль органнар белән эшләү буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Захарова<br>Светлана Михайловна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Карпов<br>Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Лаврентьев<br>Александр Петрович | Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Маврина<br>Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Мәхмүтов<br>Марсель Азат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Мөхәммәдиев<br>Рөстәм Нәбиулла улы | В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Мөхәрләмов Руслан<br>Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Поминов<br>Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Салихов<br>Кев Миңнулла улы | «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – Е.К. Завойский исемендәге Казан физика-техника институтының фәнни җитәкчесе, Россия фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фролов<br>Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |
| Хәкимҗанов<br>Ленар Сәетҗан улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |

__________».

2. Кушымта нигезендәге исемлек буенча Татарстан Республикасы Президенты указларын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 6 февраленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 03 июль
№ 461

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «03» июлендәге
461 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчен югалткан указлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы Указының 3 пункты.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составын үзгәртү турында» 2009 елның 26 мартындагы ПУ-175 номерлы Указы.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составын үзгәртү турында» 2010 елның 14 маендагы ПУ-314 номерлы Указы.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-36 номерлы Указы.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 14 мартындагы ПУ-202 номерлы Указы.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» 2012 елның 17 апрелендәге ПУ-258 номерлы Указы.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 27 июлендәге ПУ-621 номерлы Указы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 8 февралендәге ПУ-89 номерлы Указы.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 28 июнендәге ПУ-580 номерлы Указы.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы Указының 3 пункты.

11. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 29 апрелендәге ПУ-441 номерлы Указы.

12. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» 2014 елның 2 июлендәге ПУ-629 номерлы Указы.

13. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 19 сентябрендәге ПУ-897 номерлы Указы.

14. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 28 маендагы ПУ-498 номерлы Указы.

15. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 19 гыйнварындагы ПУ-17 номерлы Указы.

16. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 маендагы ПУ-422 номерлы Указы.

17. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы Указының 2 пункты дүртенче абзацы.

18. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 9 ноябрендәге ПУ-987 номерлы Указы.

19. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 3 февралендәге ПУ-96 номерлы Указы.

20. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 июлендәге ПУ-627 номерлы Указы.

21. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 18 гыйнварындагы ПУ-69 номерлы Указы.

22. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәреш кертү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-351 номерлы Указы.

23. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 31 гыйнварындагы ПУ-44 номерлы Указы.

24. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-217 номерлы Указы.

25. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 июнендәге ПУ-359 номерлы Указы.

26. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге ПУ-556 номерлы Указы.

27. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 сентябрендәге ПУ-612 номерлы Указы.

28. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 4 декабрендәге ПУ-816 номерлы Указы.

29. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 15 апрелендәге ПУ-288 номерлы Указы.

30. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 29 июлендәге ПУ-607 номерлы Указы.

31. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 22 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы.

32. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге ПУ-780 номерлы Указы.